Үзгәрешләр турында мәгълүмат:
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 3 июлендә кабул ителгән 390 нчы санлы карары нигезендә, әлеге карарның аталышы түбәндә күрсәтелгәнчә яңа редакциядә, рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.*

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

13 декабрь 2011 ел №141

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, 18 яшькә җитмәгән өч һәм өчтән дә артык балалары булган гражданнарга бушлай һәм шәхси милек итеп җир участоклары бирү тәртибен билгеләү турында

Үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән:
3 июль 2014 ел, 29 апрель 2016 ел.

Үзгәрешләр турында мәгълүмат:
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2016 елның 29 апрелендә кабул ителгән 65 нчы санлы карары нигезендә, әлеге карарның аталышы түбәндә күрсәтелгәнчә яңа редакциядә, рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.*

“Татарстан Республикасы Җир кодексына өстәмәләр кертү” турындагы 2011 елның 18 ноябре № 90–ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә:

Үзгәрешләр турында мәгълүмат:
*Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 3 июлендә кабул ителгән 390 нчы санлы карары нигезендә, әлеге карарның 1 нче пунктына үзгәрешләр кертелде һәм ул рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.*

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә даими яшәүче, 18 яшькә җитмәгән өч һәм өчтән дә артык балалары, шул исәптән үги кызы яки улы, уллыкка, кызлыкка алынган, (опека органнары тарафыннан чикләүсез вакытка аның карамагына тапшырылган балалар да керә) булган гражданнарга муниципаль милектә исәпләнүче, шулай ук, дәүләт милке булып төрле чикләүләрдән азат булган җир участокларын, бушлай һәм шәхси милек итеп, объектның кайда урнашуы хакында алдан килешмичә, шәхси торак төзелеше, дача төзелеше, бакчачылык, шәхси йорт хуҗалыгы алып бару өчен 0,6 га дан 0,20 га кадәр җир участогы бирү тәртибен билгеләргә:

2. Әлеге карар рәсми рәвештә “Знамя труда”, “Әлмәт таңнары” газеталарында басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, торак–коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (А.И.Верия) йөкләргә.

Әлмәт муниципаль районы башлыгы Р.Ф. Әбүбәкеров